**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422612, РТ, Лаишевский район,
п. Мысовский, ул.Центральная, д.33 а
тел: 89872742637,kuuk.la@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422612, РТ, Лаеш район, Мысовский
поселок, Центральная ур, 33 а йорт
тел: 89872742637, kuuk.la@tatar.ru

**2021 елның 22 гыйнваре** **1 номер**

**КАРАР**

**Көек авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 мартындагы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында " гы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 30 июнендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 февралендәге112 нче номерлы Указы белән, 2013елның 25 июнендәге N 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы белән, "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 29 сентябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының " Көек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Көек авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Көек авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 мартында кабул ителгән 3 номерлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» гы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo/tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Ю.Зотин**

*2021 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы*
*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль*
*районының* Көек *авыл җирлеге*
*советы карарына кушымта*

**Көек авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 мартындагы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында " гы 3 номерлы карарына үзгәрешләр**

1) 3.3 пунктын түбәндәге пунктлар белән тулыландырырга:

- индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсен (контракт) беренче тапкыр төзү очраклар керми;
- Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык;
- хәрби исәпкә алу документлары - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

2) 3.3 пунктындагы д пунктчасыны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

муниципаль хезмәткә кергән елдан алдагы елда керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

3) 3.2 пунктның 3.4нче абзацларын яңа редакциядә бәян итәргә:

муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кабул итә торган муниципаль хокукый акт белән билгеләнә. Конкурсны уздыру тәртибе аның шартларын, аны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турындагы белешмәләрне, шулай ук конкурс үткәрү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча хезмәт шартнамәсе проектын бастырып чыгаруны күздә тотарга тиеш. Муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны һәм аны төзү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә. Җирле администрациянең җирлектә, шәһәр округында яисә авылара территориядә урнашкан авыл торак пунктларында җирле администрация вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру йөкләнә торган территориаль органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелгән очракта,

муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясен төзү тәртибе әлеге авыл торак пунктларының һәрберсендә граждannар җыены тарафыннан күрсәтелгән кандидатураларны аның әгъзалары санына кертүне күздә тотарга тиеш.